| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2019 Казан шәһәре № 10-222/кс

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2020 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенә иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су

белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар
кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 18.12.2019
№ 10-222/кс карарына кушымта

# Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2020 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә компонент, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Егәрлек өчен ставка, аена мең сум/1 Гкал/сәг. | Җылылык энергиясе ставкасы, сум/Гкал |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 22,27 | 1527,11 | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 23,11 | 1588,19 | - | - |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)** | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 26,72 | 1832,53 | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 27,73 | 1905,83 | - | - |
| 1.2. | Яр Чаллы шәһәре | | | | | |
| 1.2.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 30,76 | 1349,98 | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 31,99 | 1403,98 | - | - |
| 1.2.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 36,91 | 1619,98 | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 38,39 | 1684,78 | - | - |

<*> «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә компонентлар исәпләмәсенә кабул ителә торган тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга

җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә 2019-2023 елларга тарифларны 2020 ел өчен үзгәртү турында» 20.11.2019 № 5-31/тэ карары белән билгеләнде.

<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге